| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ШАЛТИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШАЛТЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

25 мая 2023 г. с. Шалты № 68

Җирле салымнар суммалары өлешендә
бурычларны түләтүгә өметсез дип
тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге Уставына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) физик затның үлеменнән соң өч еллык срокның тәмамлануы яки аны гражданлык процессуаль законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә үлгән дип игълан ителүе, әгәр варислар закон буенча да, васыять буенча да булмаса, яки варисларның берсе дә мирас алудан читләштерелмәсә, яки варисларның берсе дә мирас алудан баш тартса, яки аларның барысы да мирас алудан баш тартса, һәм аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын күрсәтмәсә;

2) салым түләүченең гражданнарга стационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмада булуы;

3) гамәлдән чыгарылган җирле салымнарны түләү буенча бурыч барлыкка килгән көннән алып өч еллык срокның тәмамлануы;

4) салым салу объекты булган милеккә милек хокукы туктатылган көннән алып өч еллык срокның тәмамлануы;

5) бурычның барлыкка килү датасы өч елдан артык булган түләтү мөмкин түгеллеге турында акт булу;

6) суд приставлары тарафыннан «Башкарма производство турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль Законның 47 статьясына ярашлы рәвештә башкарма производствоны тәмамлау турында карар чыгару;

7) салым түләүче физик затның ирегеннән мәхрүм итү урыннарында, ирегеннән мәхрүм итү урыннарында булу;

8) 2006 елның 1 гыйнварына кадәр җирле салымнар буенча бурычлар булуы.

2. Үз көчләрен югалткан дип танырга:

Шалты авыл җирлеге Советының 21.11.2014 елның № 71 карары «Җирле салымнар буенча бурычларны, пени буенча бурычларны һәм бу салымнар буенча штрафларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында»;

Шалты авыл җирлеге Советының 06.10.2017 № 42 карары “Шалты авыл җирлеге Советының 21.11.2014 № 71 “җирле салымнар буенча бурычларны, пени буенча бурычларны һәм бу салымнар буенча штрафларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен җәелдерә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артымнан калдырам.

Шалты авыл җирлеге
Башлыгы, Совет рәисе                                        З.Х. Фаткуллин